| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА ТИМЕРЛЕКСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ТИМЕРЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Чуаш Тимерлеге ав. КАРАР

«2» ноябрь 2020 ел № 2

Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Тимерлек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 18 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Красномайский поселогы, Үзәк урамы, 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасы янына Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогында Үзәк урамда 1-59 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә

2. 2020 елның 20 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Красномайский поселогы, Полевая урамы, 3 нче йорт янына Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогында Полевая урамындада 1-30 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Красномайский поселогы халкының исемлеген бүлү тәртибен территориаль билге буенча сайлау тәртибе.

4. Гражданнар җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Красномайский поселогы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1 гр инвалидларыннан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Красномайский поселогы торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм вак таш катнаш грунт салу;
Красномайский поселогына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Красномайский поселогы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов